# Аеруча шат булыр идем



Таныш сукмактан атлыйм. Ферма сукмагы ул. Гомер юлым да шуңар бәйле булгангамы, аеруча күңелгә якын бу юл.

Һәр көн иртән торып бу сукмактан авыл башындагы фермага, бозауларым янына ашыгам. Килгәч тә, бер кат үзләрен сөеп-назлап чыгам, аннан исә ашатам-эчертәм. Бу вакытта әле сыер савучылар килмәгән була. Бер караганда, олыгая барган кеше өчен 30 бозау аз түгел шикелле. Эшлисе килә, әмма беләкләрнең егәре кими бара. Ә бит моннан өч-дүрт еллар элек кенә 104 баш бозау карый идем. Ничек кенә әле, яңа ысул белән. Тездән салкын карга һәрберсен күтәреп алып чыгам, күтәреп алып керәм. Дерестән дә салкын ысул белән үстергәндә бозаулар көр, йоннары да озын булып үсә. Тик менә шул вакытта үземнен аяк буыннарыма гына салкын тиеп калды, хәзер еш сызлап интектерәләр.

Фермада үзем өч дистә елдан артык бозаулар карыйм. Шул дәвер эчендә искиткеч авыр көннәр дә булды. Ул чакларда ирем авырып түшәктә ятты. 20 ел аны карадым. Иртәкич фермада, төнлә өйдә үз эшләремне эшлим. Хәзер уйлап куям да гаҗәпкә калам: ничек эшләнелгән?

Ә бит өч бала да тәрбияләп үстердем. Хәзер өлкән улым Фәрит техникум бетерде, колхозда ветфельдшер булып эшли. Рәшите—агроном, арендачы. Төпчек кызым Фәридә исә Мәләкәстә фабрикада эшли. Шөкер, балаларым да тырыш булдылар, әни дип өзелеп торалар. Тик менә аталары Фәйзерахман гына бу көннәрне күрә алмады.

Эшемдә бик мактасалар да, бер үтенечемне колхоз әлегә канәгатьләндерми. Өем искерде, йорт сорап йөрим. Шул яктан ярдәм күрсәтсәләр, аеруча шат булыр идем.

**С. ФӘЙЗУЛЛИНА.**

«40 лет Победы» колхозы.

Ремонт-техника предприятиесенең ЗИЛ-130 машинасы шоферы Александр Еремеев һәм К-700 тракторчысы Вячеслав Ендиряков җыелма отряд белән районыбыз колхозларына ярдәмгә чыгарга теләк белдергәннәр иде. Быел уңыш

# Шәһәрдән—авылга

түбән булу сәбәпле җыелма отрядны тараттылар һәм аның членнарын ярдәмгә мохтаҗ булган колхозларга гына җибәрделәр.

Шофер Еремеев белән тракторчы Ендиряков XXI партсъезд исемендәге колхозга юл тоттылар. Берсе, ягъни Вячеслав Ендиряков, 'ДОН-1500 кыр корабына утырды, ә Александр Еремеев комбайн бункерыннан ындыр табагына ашлык ташый. Әнә шундый, игенче өчен авыр көннәрдә шәһәрдән авылга ярдәмгә килгән бу эшчеләргә карата рәхмәт хисләре аеруча зур.

Рәсемдә: җыелма отряд членнары В. Ендиряков һәм А. Еремеевны күрәсез.





# Ужым чәчүгә—ныклы игътибар

**Август ае игенче өчен киеренке чор. Барысына да үз вакытында өлгерергә, һәммәсен дә игътибар үзәгендә тотарга, быелгы урып-җыюны уңышлы төгәлләү белән генә канәгатьләнмичә, икенче ел уңышына да нигез салырга кирәк. Хуҗалыкларда хәзер көн үзәгендә ужым культуралары чәчү бурычы тора. Бу хакта кайбер мәсьәләләр белән районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе баш агрономы Н. М. МУСИН таныштыра.**

Безнең шартларда инде күп еллар буе ужым культураларыннан бөртекле сабан культураларына караганда нәтиҗәлерәк уңыш алына. Ужым культураларының шундый өстенлеге аеруча язгы-җәйге корылык чорларында күзәтелә. Көзге һәм кышкы-язгы дымны вегетатив үсү өчен файдаланып һәм төп авырлыкны шул вакытта туплап, ужым культуралары көзен үк корылыктан «качалар».

Быел да шулай ук ужымнарның уңдырышлылыгы сабан һәм бөртекле культураларныкыннан күпкә артыграк. Әйтик, мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә, «Россия», Хафизов исемендәге, XXI партсъезд исемендәге, «Комбайн» колхозларында ужымнарның уңдырышлылыгы гектарыннан 25,2—35,0 центнер тәшкил итте.

Шулай да ужымнарның потенциаль мөмкинлекләре тулысынча файдаланылмый әле. Елдан-ел колхоз һәм совхозлар шактый гына мәйданнарда ужымнарның һәлак булуына, уңдырышның кинәт кимүенә китерә торган хаталарны кабатлап торалар. Мәсәлән, шундыйларын әйтеп үтү зарур: элгәре бөртеклеләр булган җиргә чәчү, чәчү срокларын бозу, азотның башка элементлар белән нисбәте нигезсез рәвештә бозылуы, чәчүлекләрнең корткычлардан, авырулардан сакланмавы, чәчү материалларының түбән сыйфаты, туфракны сыйфатсыз һәм соңарып эшкәртү.

Агымдагы елда, елы ужымнар өчен кырыс булмаса да, шул сәбәпләр 1937 гектарда ужымны кире чәчергә мәҗбүр иттеләр. Синдряков исемендәге, «Таң», «1 нче Май» колхозлары һәм «Сөлчә» совхозы 150—260 ар гектар җирдә кире чәчтеләр.

Ужымнар өчен иң яхшы булып сидераль һәм чиста пар җирләре санала. Шулай ук рапс, берьеллык һәм күпьеллык үләннәрне бер тапкыр урдыртаннан соң һәм борчак артыннан да чәчәргә мөмкин. Бөртекле башаклы культуралардан соң чәчү һич тә ярамый, ул үсемлекләрнең туклануын боза һәм корткычлар, авырулар белән көчле зарарлануына китерә.

Ашламалар куллану да уңдырышлылык артуга нык тәэсир итә. Шунлыктан чәчү алдыннан чәчүлек җирләрнең ашламаларга ихтыяҗларын мөмкин кадәр күбрәк канәгатьләндерергә кирәк. Ужымнарның бер гектары да ашламасыз чәчелмәскә тиеш. Бу—мәҗбүри шарт. Һәр планлаштырылган центнер ашлык өчен туфракта 1,2—1,3 килограмм фосфор, 2,5—2,6 килограмм алыштыра торган калий булырга тиеш. Шуларны исәпкә алып кына ашламалар кертүне алып барырга ярый. Фосфорлы һәм калийлы ашламалар башка якларыннан битәр үсемлекләрнең салкынга каршы торучанлыгын һәм авыруларга каршы ныклыгын арттыралар. Тагын шунысы бар: ужым чәчеләчәк чиста пар җирләренә азотлы ашламаларны бары тик тукландыру йөзеннән икенче елда гына кертергә кирәк.

Туфракны үз вакытында һәм сыйфатлы итеп эшкәртү киләсе ел уңышында мөһим роль уйный. Комплекслы агрохимик культуралаштыру үткәрелгән, җәй буена чүпләрдән арындырылган чиста пар җирләрендә орлык чәчү тирәнлегендә культивация үткәрү дә җитә.

Күп кенә хуҗалыклар еш кына берьеллык, катнаш азык үләннәреннән азат ителгән һәм борчак участокларын ике юнәлештә күп төрәнле сай сөргеч белән эшкәртәләр. Алга таба яссы кискечләр белән эшкәртү туфракның нормаль бүленешен тәэмин итә.

Ашлык җитештерүне арттыруның икенче мөһим факторы—интенсив һәм югары сортлы орлык чәчү. «Чулпан», «Саратов-5», «Безенчук-87» сортлы арыш, «Казан-84», «Мещенск» сортлы ужым бодае нәкъ шул таләпләргә җавап бирәләр. Аларның потенциаль уңдырышлылыгы 60—70 әр центнер тәшкил итә. Соңгы ике сортның кышка чыдамлылыгын да әйтеп үтәргә кирәк, ә бу сыйфат безнең шартларда мөһим роль уйный.

Күчмә фондтагы орлык чәчү дә гектарыннан 3—5 центнерга артыграк уңыш бирә. Ульянов исемендәге, «Россия», XXI партсъезд исемендәге, «Таң», «Заря» колхозлары нәкъ шуңа игътибар бирәләр.

Чәчү алдыннан орлыкларны инкрустацияләү зарур, моның өчен фундозол һәм микроэлементлар (бакыр сульфаты, цинк, марганец) кулланырга кирәк.

Чәчү вакыты—уңдырышлылыкның төп факторы булып тора. Иртә чәчсәк, буйга үсеп китәләр, шуңа аларны яшерен сабактагы корткычлар зарарлый, авырулар китереп чыгара. Ә соңрак чәчелгәннәр өлгереп җитмиләр. Ике очракта да ужымнар кышкы чорда күбрәк зарар күрәләр.

Парсыз җирләрдә унынчы августтан соң, ә чиста һәм сидераль пар җирләренә 20—25 августларда чәчү нәтиҗәлерәк була. Августның соңгы декадасы ужым бодае чәчү өчен иң оптималь срок. Чәчелгән ужымнар өстен авыр катоклар белән тәгәрәтеп чыгарга кирәк.

Ужым арышы өчен оптималь норма гектарына 4,0—4,5, ә ужым бодае өчен 6,0—6,5 миллион бөртек. Арыш авыр чәчүлекләрдә 3—4 сантиметр, җиңел чәчүлекләрдә 4—5 һәм ужым бодае 6—7 сантиметр тирәнлектә чәчелергә тиеш.

Сентябрьнең уртача җылылыктан артып киткән чакларында артык үсеп китүен булдырмас өчен һәм шул сәбәпле кардан зарарланмасын өчен фундозол катнашмасын ТУР препараты ярдәмендә дә эшкәртү зарур.

## 1992нче ел уңышы астында чәчелергә тиешле ужым культуралары (гектарларда)

**Беренче багана—хуҗалыклар исеме, икенче—барлык чәчү планы, өченче—шул исәптән ужым бодае, дүртенче—ужым культуралары бөртеклеләргә карата (процентларда).**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 719 | 160 | 43 |
| Ульянов исем. | 782 | — | 39 |
| «Правда» | 708 | — | 47 |
| «Восход» | 600 | 150 | 40 |
| Мичурин исем. | 695 | 90 | 51 |
| «Россия» | 550 | 150 | 42 |
| Хафизов исем. | 734 | 50 | 68 |
| «Путь к коммунизму» | 1030 | 80 | 55 |
| Муса Җәлил исем. | 650 | 50 | 58 |
| «Родина» | 550 | 100 | 51 |
| «Игенче» | 1000 | — | 53 |
| «Большевик» | 600 | 100 | 47 |
| «Заветы Ильича» | 932 | 60 | 60 |
| «Знамя Октября» | 1200 | 600 | 67 |
| «Алга» | 1600 | 800 | 51 |
| «Комбайн» | 1500 | 600 | 62 |
| XXI партсъезд исем. | 1360 | 600 | 44 |
| «Татарстан» | 1050 | 250 | 65 |
| «40 лет Победы» | 646 | 170 | 46 |
| «Чишмә» | 825 | — | 46 |
| «Таң» | 612 | — | 60 |
| «Москва» | 690 | 80 | 50 |
| «Үрнәк» | 410 | 85 | 47 |
| «Лесная Поляна» | 130 | 25 | 56 |
| «Кондырча» | 425 | — | 67 |
| Кузнецов исем. | 694 | 464 | 51 |
| «Заря» | 650 | — | 58 |
| «Чирмешән» | 390 | — | 60 |
| «Ленинский путь» | 650 | 100 | 50 |
| «Беренче Май» | 810 | 200 | 45 |
| «Төрнәс» совхозы | 1140 | 510 | 51 |
| «Мамык» совхозы | 879 | 629 | 53 |
| «Рассвет» совхозы | 1566 | — | 66 |
| «Сөлчә» совхозы | 920 | — | 59 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 250 | 110 | 62 |
| Дуңгызлар симертү буенча хуҗалыкара берләшмә | 200 | — | 37 |
| Район буенча | 28147 | 6173 | 52 |

